Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы

24 гыйнвар, 2014 ел. Боерык №2

Казан ш.

**“Смарт Сити Казан” Халыкара инвестиция технополисы резидентларын - инвесторларын (катнашучыларын) билгеләү методикасын раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.09.2013 елдан “СМАРТ Сити Казан” Халыкара инвестиция технополисын булдыру турындагы № 1874-р боерыгын башкару максатында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. “Смарт Сити Казан” Халыкара инвестиция технополисы резидентларын - инвесторларын (катнашучыларын) билгеләү методикасын кушымтага нигезләнеп расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Л.Г. Якупов

Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентлыгының
24.01.2014 елдан №2
боерыгына кушымта

# “СМАРТ Сити Казан” ХАЛЫКАРА ИНВЕСТИЦИЯ ТЕХНОПОЛИСЫ РЕЗИДЕНТЛАРЫН - ИНВЕСТОРЛАРЫН (КАТНАШУЧЫЛАРЫН) БИЛГЕЛӘҮ МЕТОДИКАСЫ

Әлеге “СМАРТ Сити Казан” Халыкара инвестиция технополисы резидентларын - инвесторларын (катнашучыларын) билгеләү методикасы “СМАРТ Сити Казан” Халыкара инвестиция технополисы резиденты - инвесторы (катнашучысы) статусын сайлап алу һәм бирү процедурасын тәртипкә салу максаты белән эшләнде. “СМАРТ Сити Казан” Халыкара инвестиция технополисы резиденты - инвесторы (катнашучысы) статусын сайлап алу һәм бирү Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 1. Терминнар һәм нигезләмәләр:

“СМАРТ Сити Казан” Халыкара инвестиция технополисы (алга таба - технополис) **резиденты - инвесторы (катнашучысы)** - ул Татарстан Республикасының вәкаләтле хакимият органының тиешле карары белән танылган, технополис урнашкан муниципаль оешма территориясендә Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлүче, яисә әлеге территориядә салым исәбендә (икенчел салым исәбендә) торучы һәм технополиска бүлеп бирелгән территориядә инвестиция һәм/яки коммерция эшчәнлеген башкаручы юридик зат яисә шәхси эшмәкәр.

**Инвестиция проекты** – капитал салуның икътисади максатчанлыгын, күләмнәрен һәм вакытларын нигезләү, шул исәптән кирәкле проект документлары, һәм шулай ук инвестицияләрне (бизнес-планны) гамәлгә ашыру буенча тәҗрибә эшләрен тасвирлау.

**Технополис операторы** – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.09.2013 елдан, №1874-р боерыгы нигезендә “Татарстан Республикасының Үсеш корпорациясе” Ачык акционерлык җәмгыяте.

**Татарстан Республикасының вәкаләтле хакимият органы** - Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.09.2013 елдан, №1874-р боерыгы нигезендә контрольлек итүгә һәм технополисны булдыруны һәм,

шул исәптән, инвестицияләрне җәлеп итү һәм дәүләт-шәхси партнерлык механизмнарын куллану юлы белән эшчәнлек башкаруны көйләүгә вәкаләтләнгән орган.

**“СМАРТ Сити Казан”ның Яшел регламенты** - төзелеш технологиясенә, төзелеш материалларына, җирдән файдалануга һәм төзегән объектларның киләчәктәге файдаланышына карата кулланылучы экология стандартлары һәм таләпләре. Технополис операторы тарафыннан ирекле сертификация өчен эшләнә.

**Инвестиция тәкъдиме** – Татарстан Республикасының вәкаләтле хакимият органына бирелгән һәм инвестиция проекты, технополис территориясе зонасында инвестиция һәм/яки коммерция эшчәнлеген башкару турындагы мәгълүматларны үз эченә алган документ. **Инвестиция эшчәнлеге** – табыш алу һәм (яисә) башка файдалы нәтиҗәгә ирешү максатларында инвестицияләр салу һәм тәҗрибә эшләрен башкару.

## 2. Технополис резидентын - инвесторын (катнашучысын) билгеләү тәртибе.

2.1. Технополис резиденты - инвесторы (катнашучысы) статусын алу өчен түбәндәгеләр тиешле:

- методиканың 4 п. нигезендә инвестиция тәкъдименә карата куелучы таләпләргә туры китерелгән һәм технополисның резидентларын - инвесторларын (катнашучыларын) билгеләүнең методиканың 3 пунктындагы төп критерийлары исәпкә алынган инвестиция тәкъдимен Татарстан Республикасының вәкаләтле хакимият органына ирекле язма формада тапшырырга. Инвестиция тәкъдиме вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш.

Инвестиция тәкъдименә түбәндәгеләр теркәлә:

1) оештыру документларының күчермәләре (юридик затлар өчен – Устав, оештыру турындагы карар), нигезләмәләрнең күчермәләре (филиаллар һәм вәкиллекләр өчен);

2) юридик затның дәүләт теркәве турындагы таныклыгының күчермәсе, физик затның шәхси эшмәкәр буларак дәүләт теркәве таныклыгының күчермәсе;

3) салым органында исәпкә куелу турындагы таныклыкның күчермәсе.

Инвестиция тәкъдимен тапшырган зат, аның нигезләмәләрен аныклау һәм конкретлаштыру өчен, өстәмә документларны һәм инвестиция проектына һәм аны башкаруның тәртибенә карата мәгълүматны тапшырырга хокуклы.

2.2. Татарстан Республикасының вәкаләтле хакимият органы тапшырылган документларны инвестиция тәкъдиме тапшырылган көннән башлап утыз көн эчендә карый.

2.3. Тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының вәкаләтле хакимият органы Боерык формасында инвестиция тәкъдимен тапшыручы затны технополисның резиденты - инвесторы (катнашучысы) итеп тану, яисә аны шундый дип танудан баш тарту турында карар чыгара.

2.4. Чыгарылган карар турында Татарстан Республикасының вәкаләтле хакимият органы өч көн эчендә инвестиция тәкъдимен тапшыручы затка җиткерә. Әлеге карар законнарда каралган тәртиптә шикаять кылынырга мөмкин.

**3. Технополис резидентларын - инвесторларын (катнашучыларын) билгеләүнең төп критерийлары.**

3.1. Инвестиция тәкъдименең "СМАРТ Сити Казан" Халыкара инвестиция технополисының Үсеш концепциясе белән расланучы Генераль планына һәм технополис территориясендә вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителгән Мастер-планда расланган Төзү һәм җирдән файдалану кагыйдәләренә туры килүе.

3.2. Инвестиция тәкъдименең кыйммәт критерийларына туры килүе. Соралучы мәйданга карта гамәлгә ашырылучы проектның бәясе бирелгән мәйданның бер гектарына 200 000 000 (Ике йөз миллион) сумнан ким булмаска тиеш.

3.3. Инвестиция тәкъдименең социаль күрсәткечкә ия булуы. Инвестиция тәкъдименең социаль параметрларын күрсәтү һәм нигезләү, шул исәптән: булдырылучы эш урыннарының саны (30дан да ким булмаган), уртача хезмәт хакы (инвестиция тәкъдимен тапшыру көненә карата Татарстан Республикасы буенча уртача күрсәткечтән дә ким түгел), барлык дәрәҗәдәге бюджетларга һәм фондларга планлаштырылучы мәҗбүри бүленгән суммалар, технополис инфраструктурасының (объектка күрсәтеп) үсеше.

3.4. Инвестиция тәкъдименең төзелешнең, төзелештә технологияләр куллануның һәм объектның киләчәктәге файдаланылышының "СМАРТ Сити Казан"ның Яшел регламенты буенча экология стандартларына туры килүе.

3.5. Инвестиция тәкъдименең бүлеп бирелгән мәйдандагы төзү вакытының өч елдан артмаган срокларга туры килүе.

**4. Инвестиция тәкъдименә карата куелучы таләпләр.**

4.1. Инвестиция проектын технополис территориясе зонасында гамәлгә ашыру.

4.2. Инвестиция проектында каралган икътисади эшчәнлек төрләренең “СМАРТ Сити Казан” Халыкара инвестиция технополисының Үсеш концепциясенә туры килүе.

4.3. Инвестиция тәкъдимендә түбәндәге мәҗбүри мәгълүматның булуы:

- инвестиция проектында каралган инвестиция эшчәнлегенең максаты;
- инвестиция эшчәнлеге объекты турында мәгълүматлар һәм аның кыскача сыйфатламасы (мәйданы, катлар саны, объектлар (комплекслар) составы, җитештерү егәрлеге, күрсәтелүче хезмәтләрнең күләме һәм инвестиция тәкъдимен тапшырган затның ихтыяры буенча башка күрсәткечләр);
- инвестиция проектын финанслауның гомуми күләме;
- инвестиция проектын гамәлгә ашырганда, шул исәптән беренче этапта (беренче ел) инвестицияләрне башкаруның күләме һәм графигы;
- технополис резиденты - инвесторы (катнашучысы) сыйфатында фаразланучы эшчәнлек турында мәгълүматлар;
- инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен бар булган яисә кирәкле булган мәйдан һәм файдалану өчен рөхсәт ителгән җир кишәрлегенең төре турында мәгълүматлар (ирекле формада).

**5. Технополис резидентларына - инвесторларына (катнашучыларына) карата таләпләр**

5.1. Инвестиция тәкъдименең методиканың төп критерийларына һәм таләпләренә туры килүе һәм инвестиция тәкъдимен тапшырган затны технополис резиденты - инвесторы (катнашучысы) итеп тану турында Татарстан Республикасы вәкаләтле хакимият органының карары булу.

5.2. Инвестиция проектын тормышка ашыру урыны буенча юридик зат яисә филиал, вәкиллек, юридик затның аерым бүлекчәсе, шәхси эшмәкәр төсендә салым исәбенә куелу.

5.3. Түбәндәгеләрдән баш тарту:

- технополис территориясендә акциз салымы салынучы товарларны җитештерүдән;
- файдалы казылмаларны табу һәм урнаштырудан;
- уен бизнесын башкарудан.

5.4. Технополис территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда инвестиция эшчәнлеген көйләүче законнарны һәм башка норматив-хокукый актларны, шул исәптән Татарстан Республикасы

Инвестицион үсеш агентлыгының 24.01.2014 елдан № 4 боерыгы белән расланган “СМАРТ Сити Казан” резидентлары - инвесторлары (катнашучылары) тарафыннан җирдән файдалану һәм территориядәге төзелү тәртибен, шартларын регламентлаучы килешү һәм башка төр документларны килештерү тәртибе”н үтәү;

5.5. Иинвестиция процессын башкару һәм алып бару, инвестиция проектын гамәлгә ашыру тәртибе буенча, Татарстан Республикасының вәкаләтле хакимият органының көйләүче актларыннан файдалану буенча Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының 24.01.2014 елдан №3 боерыгы белән расланган “СМАРТ Сити Казан” Халыкара инвестиция технополисының Проект операторы турындагы Нигезләмә”се нигезендә эш итүче Технополис операторының бәяләмәләрен һәм киңәшләрен үтәү.

5.6. Югарыда күрсәтелгән таләпләрне үтәмәү Татарстан Республикасының вәкаләтле хакимият органының Боерыгы формасында технополис резиденты - инвесторы (катнашучысы) статусын югалты белән яный, ул законнарда каралган тәртиптә шикаять кылынырга мөмкин.